ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/7

Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

2018 елның 03 августындагы «Россия Федерациясе Салым кодексының 52 маддәсе икенче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 334-ФЗ санлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезеләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 21/8 санлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктта:

- 1 пунктчаның икенче абзацын «шул исәптән әлеге Карарның 2 пункты 4,5 пунктчаларында күрсәтелгән салым түләү объектларында урнашкан» сүзләре белән тулыландырырга;
- 2 пунктчаның икенче абзацын «, фатирлар өлеше» сүзләре белән тулыландырырга;
- 3 пунктчаның бишенче абзацын «, торак йортларның өлеше» сүзләре белән тулыландырырга;

2) 4 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) гомуми мәйданы 100 квадрат метрдан артмаган торак йортның бер өлеше, фатир, фатир өлеше, бүлмә яки торак йорт өлешләре»;

3) 4 пунктның алтынчы абзацында «машина кую урыны» сүзләреннән соң «шул исәптән әлеге карарның 2 пункты 4,5 пунктчаларында күрсәтелгән салым түләү объектларында урнашкан» сүзләрен өстәргә.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев